СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
29 май 2020 ел

**КАРАР**
№ 182

**Чепья авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында Балтач муниципаль районы**

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2009 елдагы 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында 14.11.2013 ел, № 86 (24.03.2014 ел, № 105, 23.06.2017 ел, № 78, 30.09.2009 ел, № 159 үзгәрешләр белән) расланган Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Нигезләмәнең 29 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә..

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru к

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау, яшелләндерү, төзекләндерү, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Чепья авыл
җирлеге башлыгы

А.Г. Нотфуллин